Ислам нуры

إسلام نورى

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№ 6 (658) 27 март, 2018 ел (1439, Рәҗәб) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

2018 ел – Шиһабетдин Мәрҗани елы

Татар ханнарын барлаучы

***Ш**иһабетдин Мәрҗани – татар тарихы белеменә нигез салучы, гомум төрки-татар тарихын, Казан татарлары тарихын бербөтен итеп берләштерүче. Ул үзенең хезмәтләрендә татар этносы яшәгән территорияләрнең барлык өлешен диярлек өйрәнеп чыга, шуның белән гомуммилли тарихыбызны гамәлгә куя. Татарларның рухи башкаласы буларак, Казан тарихын өйрәнү нәкъ менә Мәрҗанидән башлана.*

Беренче татар сәясәтчесе Рәшит казый Ибраһим 1915 елда Казанда дөнья күргән «Мәрҗани» исемле җыентыкта басылган мәкаләсендә олуг галимне болай бәяли: «Мәрҗани — татарлар арасында беренче мәгърифәтчеләренең берсе иде дип уйлыйм, ул үзенең каләме белән татар ханнарының тузан каплаган, югалган исемнәрен иң беренче булып санап чыкты». Шуңа күрә Мәрҗанине «татар Геродоты», ягъни татар тарихының атасы дип атыйлар.

Киңәшле эшнең киме булмас...

17 мартта Чаллының “Ак мәчете”ндә “Җәмгыять тормышын тотрыкландыруда Ислам диненең әһәмияте” дигән темага III Халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Анда “Ак мәчет” мәдрәсәсе директоры, төбәк казые Рөстәм хәзрәт Шәйхевәли, Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Болгар академиясе укытучысы Әбдерразак әс-Сәгъди, Словакия республикасыннан “Кеше һәм аның хокуклары” гражданлык җәмгыяте рәисе Эмиль Хәмидуллин, Мәскәү лингвистик университетының фәлсәфи фәннәр кафедрасы мөдире Айдар Каюмов, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы мөдире Алмас Шәйхуллов, Рәсәй Ислам институты ректоры, Болгар академиясе ректоры, сәяси фәннәр докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин, академик Мирфатыйх Зәкиев, филология фәннәре докторы Марсель Бакиров, тарих фәннәре докторы Айдар Хәбетдинов катнашты; кунаклар үз фикерләре белән дә уртаклаштылар. Әс-Сәгъди галимнәре булмаган халыкның юкка чыгачагы хакында искәртте, Болгар академиясе ачылуны зур казаныш дип атады. Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин Татарстанда Ислам мәгарифенең барлыкка килүе, инде тормышка кергән өч баскычлы уку системасы стандартлары, кадимчелек һәм җәдитчелек традицияләре, аларның бүгенге дини белем бирүдә чагылышы турында тәфсилләп сөйләде. “Ак мәчет” мәдрәсәсенең фәнни конференцияләр уздыру буенча башлангычын хуплады, бу тәҗрибәне өйрәнәчәкләрен һәм башка урта мәдрәсәләрдә дә бу эшне җәелдерәчәкләрен белдерде. Мирфатыйх аганың чыгышы бүгенге чорда татар телен саклап калу бурычларына багышланды.

Балалар да бәйгедә, яшьләр дә

Чаллы шәһәренең “Нур-Ихлас” мәчетендә Чаллы имамнарының чираттагы мөхтәсибәт утырышы булып узды. Алда торган ике зур чара — балаларның республикакүләм Коръән уку бәйгесе һәм мөселман яшьләренең татарча көрәш, кул көрәше турнирын үткәрү буенча фикер алыштылар.

Коръән уку бәйгесе егерме өченче ел рәттән уздырыла, быел өч йөзгә якын баланың Коръәнне яхшы белү буенча белемнәрен бәяләү белән аерылып торачак. Әлеге чара балаларның язгы каникул чорында — 28 мартта “Ак мәчет” мәдрәсәсе бинасында узачак, иртән сәгать тугызда башланачак.

Бәйгенең оештыручылары — Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Чаллы мөхтәсибәте, “Ислам нуры” дини-эшмәкәрлек үзәге.

Мөрәҗәгать итү өчен телефоннар: 56-65-99, 38-67-02.

***

7 апрельдә Чаллының “Витязь” спорткомплексында мөселман яшьләренең татарча һәм кул көрәше буенча X берләштерелгән Республика ачык турниры узачак. Турнирда фәкать намаз укучылар гына катнаша ала. Шуңа күрә алар башта намаз гыйбадәтен белү буенча әңгәмә узалар. Турнир ахырында үз төркемнәрендә җиңүчеләр арасында шобага салу уздырыла һәм анда отучы турнирның иң олы бүләге — хаҗга юллама белән бүләкләнә. Былтыр мондый бәхет Түбән Кама егете, кул көрәше буенча чемпион Илгиз Нәфыйковка елмайды. Калган җиңүчеләргә дипломнар һәм акчалата призлар тапшырыла. Җиңүче команда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте кубогына ия була. Турнирда Татарстаннан читтәге төбәкләрдән дә мөселман спортчылары башкалар белән тигез шартларда көч сынаша. Рәхим итегез!

Колак салсаң, үкенмәссең

* Кешенең иң куәтле коралы – зирәк акыл

* Иң начар адашу – тугры юлны тапканнан соң адашудыр

* Кешене кеше итүче, аны Аллаһка якын итүче вә ахирәттә күтәрүче бердәнбер фазыйләт – канәгатьлектер

* Вөжданнан башка бөтен нәрсәне су белән юу мөмкин

* Кем ки дошманлыкны чәчсә, мәшәкатькыенлыкны урыр

*Тәкәбберлек һичкемнең кадер-кыйммәтен арттырмас, ул давыл эчендәге бер җил генә булып тора

* Шөкер белән нигъмәткә кимү килмәс

ӘДӘП

Мөэмин-мөселман башкалардан әдәплелеге, әхлаклылыгы белән аерылып тора. Әдәп — ул тәрбиялелек, яхшы холык, үз-үзеңне тота һәм башкалар белән аралаша белү.

Әдәп эчке байлык булса да, кешенең кылган гамәлләреннән күренә. Әдәплелеге белән адәм баласы Аллаһы Тәгаләнең башка мәхлукларыннан аерылып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) еш кына Аллаһыга итагать итеп дога кылган һәм үзен күркәм әхлак сыйфатлары белән бизәвен сораган: “Әй Аллаһ, Син минем кыяфәтемне күркәм иттең, холкымны да күркәм ит!” Сәхабәләр әдәпкә аның күркәм яшәү рәвешен күреп өйрәнгәннәр.

Әнәс бине Мәлик разыйАллаһу ганһү әйткән: “Мин Аллаһның рәсүленә ун ел хезмәт кылдым. Бер мәртәбә дә аның ямьсез сүз сөйләгәнен ишетмәдем. Беркайчан да: “Бу эшне ник болай эшләдең?” — дип ачуланганын күрмәдем,” — дигән.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) болай дип дога кылган: “Әй Аллаһ, начар әхлак сыйфатларыннан Сиңа сыенам!” Аллаһ аның догасына җавап итеп, “Мөэмин” сүрәсенең 60 нчы аятен иңдергән: “Миңа дога кылыгыз һәм Мин сезгә җавап бирермен!”

Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) Коръән иңдергән, аның белән тәрбияләгән һәм шуның нәтиҗәсендә Коръән аның холкына әйләнгән. Коръән тәрбия чарасы булган. Пәйгамбәребез (с.г.в.): “Миңа тәрбияне Аллаһ үзе бирде, һәм бу тәрбия нинди күркәм булды,” — дигән.

Әгәр кеше үзен иманлы дип саный икән, ул әдәпле, әхлаклы булырга тиеш. Әгәр кеше әдәп кагыйдәләрен үтәмәсә, ул Аллаһы Тәгаләнең юлында югары дәрәҗәләргә ирешмәс, Раббысына якын була алмас, чөнки хак мөселманның билгесе — әдәп.

Әдәп — ул иманлы кешенең иң зур байлыгы, хәзинәсе. Ул кешене, үз чиратында, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм ризалыгына илтә. Танылган әүлияләрнең берсе: “Остазым миңа һәрвакыт ятимнәргә, фәкыйрьләргә, мохтаҗларга, авыруларга ярдәм күрсәтергә, аларга хезмәт итәргә куша иде. Җиде ел буе Аллаһының мәхлукларына хезмәт иттем, аларга карата әдәпле булырга тырыштым һәм шушы әдәп аркасында Аллаһы Тәгалә кальбемне ачты. Мин мәхлукларның Аллаһка ялваруларын ишетә башладым,” — дигән.

Әдәпкә ия булыр өчен рухи тәрбия кирәк. Рухи тәрбия бирү һәрбер ата-ананың, укытучының, тәрбияченең изге бурычы. Галимнәр әдәпне берничә төргә бүлгәннәр:

- Аллаһы Тәгаләгә карата әдәп.
- Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) карата әдәп.
- Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) варисларына, ягъни галимнәргә һәм әүлияләргә карата әдәп.
- Барча мәхлукларга карата әдәп.

Аллаһы Тәгаләгә карата әдәпле кеше начар, гөнаһлы гамәлләрдән ерак була, үзенең хаталарын, кимчелекләрен төзәтергә тырыша. Ул үзенең яхшылыклары белән алданмый. Кешедә изге гамәлләр никадәр күп булса да, алар Аллаһның рәхмәте, юмартлыгы белән бирелгән. Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр өчен тулысынча шөкерана кылып бетерә алмыйбыз. Аллаһка карата әдәпле булган кеше үз Раббысына һәрвакытта шөкерана кыла, изге гамәлләр эшли. Ул Раббысы язган тәкъдиреннән зарланмый. Әгәр аңа бер авырлык килсә, иң беренче чиратта гаепне үзендә эзләячәк. Бәлки мин Раббым Аллаһка карата әдәпсезлек кылганмын, бәлки мин нәфескә ияргәнмен, дип уйлаячак. Галәмнәр Раббысына әдәпле булган кеше Аллаһның барлык нәрсәнең хуҗасы икәнен онытмый.

Давыд Таи дигән галим сөйләгән: “Мин егерме ел буе бөек галим Әбү Хәнифә белән тордым. Шул вакыт эчендә мин бер мәртәбә дә аның кешеләр арасында һәм ялгыз булганда баш киемсез булганын һәм ял итәргә теләсә, беркайчан да аякларын сузып утырганын күрмәдем. Бервакыт сорадым: “Хәзрәт, ни өчен сез үзегез генә булган вакытта да аякларыгызны сузып утырмыйсыз?” — дидем. Ул җавабында: “Һәрвакыт, бөтен җирдә Аллаһы Тәгаләгә карата әдәп кагыйдәләрен үтәргә тырышам, чөнки Аллаһ мине һәрвакытта да күреп тора,” — диде.

Кайбер заһидлардан риваять ителә: “Мәчеттә һичнәрсәгә таянмадым, янә ул мәчетләрдә аягымны сузмадым, янә дөнья сүзен сөйләшмәдем”. Ягъни ошбу заһид үзе кебек булырга — мәчеттә һичнәрсәгә таянмаска, терәлмичә утырырга, утырганда аякларны сузмаска һәм дә мәчеттә бары тик гыйбадәт кенә кылырга, дөнья сүзен сөйләмәскә куша.

Мәзһәбебез имамы Әбү Хәнифә хәзрәтләре намаз вакытында гына түгел, Аллаһы Тәгаләгә әдәп йөзеннән һәрвакытта да башына киеп йөргән. Шулай булгач, башка һәрвакыт киеп йөрү, утырганда аякларны сузмыйча утыру әдәплелек кагыйдәләренә керә.

Сәхабәләрнең үзләрен мәчеттә тотышлары да сокланырлык. Хәләф бин Әюбтән риваять ителә. Дөреслектә, ул мәчеттә утыра торган булды, аның янына колы килде һәм аннан бер нәрсә сорады. Хәләф ибн Әюб торды һәм мәчеттән чыкты. Моннан соң ул колга җавап бирде. Аңардан: “Ник болай кылдың?” — дип сорадылар. Хәләф бин Әюб әйтте: “Фәлән елдан бирле мәчеттә дөнья сүзен сөйләмәдем. Бу көндә дә сөйләшүемне мәкруһ күрдем.”

Ә без, җәмәгать, үзебезне мәчеттә ничек тотабыз? Мәчеткә килгәндә ни рәвешле киенеп киләбез? Башыбызга киелгәнме, өс киемебез, аяк киемебез чистамы? Аяк киемнәрен кая һәм ничек куябыз? Намаз бүлмәсенә кергәч, соңрак килгәннәргә урын калдырып, ишек янында түгел, эчкәрәк үтсәк, нинди күркәм булыр иде. Шулай ук, дөнья хәлләрен сөйләшүне мәчеттә дәвам итмәсәк, гыйбадәт белән генә шөгыльләнсәк, мәчеткә ни өчен килгәнне аңлар идек. Мәчеткә кергәндә кәрәзле телефоннарны сүндереп керсәк, үзебезгә дә, кардәшләребезгә дә комачау итмәс идек. Намаз укыганда, вәгазь тыңлаганда барыбер телефонны куллана алмыйбыз.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: “Ул белә җиргә кергән нәрсәне һәм җирдән чыккан нәрсәне, күктән иңгән нәрсәне һәм күккә ашкан нәрсәне белеп тора. Сез кайда гына булсагыз да, Аллаһ сезнең беләндер. Аллаһ кылган гамәлләрегезне күреп тора”. (“Хәдид” сүрәсе, 4 аять)

Сәхабәләр сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) карата һәрвакыт әдәпле булганнар. Алар: “Без Аллаһының расүле саллАллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсыйхәтләрен тыңлаганда, күңелләребез Раббыбыз Аллаһка һәм Аның Пәйгамбәре Мөхәммәдкә (с.г.в.) карата мәхәббәт һәм әдәп белән тула иде. Әйтерсең лә башларыбызга кошлар кунган һәм әгәр без хәрәкәтләнсәк, ул кошлар очып китәр иде“, — дигәннәр.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә пәйгамбәрләрнең исемнәре белән, ә соңгы пәйгамбәргә “Йә Мөхәммәд”, “Йә Нәби”, “Йә Рәсүл” дип эндәшә.

“Нур” сүрәсенең 63 нче аяте: “Бер-берегезне чакырган кебек, Пәйгамбәрне дә шулай чакырмагыз, йә рәсүлуллаһ, йә нәбийаллаһ, дип дәшегез. Дөреслектә Аллаһ белде сезләрдән рөхсәт сорамыйча, бер-берсенә яшеренеп рәсүлүллаһ мәҗлесеннән чыгып китүчеләрне. (Йә Хандак казыганда рөхсәтсез ташлап китә иделәр, алар монафикълардыр.) Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) әмерләренә каршылык күрсәткән кешеләр саклансыннар, дөньяда аларга бәлаказа килүдән яки ахирәттә рәнҗетүче газаб тотудан!”

Ошбу аять иңгәнче, кешеләр Аллаһның Рәсүленә “Йә Мөхәммәд”, “Йә Әбүлкасыйм” дип эндәшәләр иде. Аллаһы Тәгалә, аның дәрәҗәсен күтәрер өчен, алай дип әйтүне тыйды, шуннан соң кешеләр Пәйгамбәребезгә (с.г.в.) “Йә Нәби”, “Йә Рәсүл”, дип эндәшә башлаганнар.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән: “Мөэминнең зирәклегеннән куркыгыз, чөнки ул Аллаһының нуры белән карый”. Чын галимнәр безгә Аллаһы Тәгаләнең кануннарын җиткерәләр, аларның тырышлыклары белән динебез көчәя һәм тарала. Алар турында хәдис-шәрифтә әйтелгән: “Галимнәр — пәйгамбәрләрнең варислары”, ягъни галимнәр пәйгамбәрләрнең эшләрен дәвам итүчеләр. Әдәп йөзеннән, галимнәр чыгарган хөкемнәрне тыңлап, динебезне алар аңлатканча тотарга тиешбез.

Әгәр кеше Аллаһы Тәгаләгә, сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә (с.г.в.) һәм галимнәргә карата әдәпле булса, ул барлык мәхлукларга карата да әдәпле булырга тырышачак, чөнки әдәплелек берьяклы гына булмый.

Раббыбыз Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә барчабызга да әдәпле, әхлаклы булып, рухи камиллеккә ирешергә насыйп итсә иде. Амин!

Равил хәзрәт Нуруллин,
Чаллының “Туфан” мәчете имам-хатыйбы.

Мигъраҗ кичәсе

Рәҗәб аеның 26 нчы көненнән 27 нче көнгә каршы киче — Мигъраҗ кичәседер. Мигъраҗ сүзе “күккә ашу” дигән мәгънәне белдерә. Аллаһның бөек кодрәте белән Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бу изге кичтә гадәти булмаган сәфәр кыла. 621 елның бер төнендә Пәйгамбәребез ястү намазыннан соң Кәгъбәтуллада гыйбадәт кылгач, Кәгъбә диварына таянып йокымсырап утырган чакта, аның янына Җәбраил фәрештә килә һәм шулай ди: “Әй Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә беркемгә дә насыйп итмәгән шәрәфне сиңа насыйп итте. Сине янына чакыра”. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд Борак (“яшен тизлегендә оча торган” мәгънәсендә) дип аталган җанварга атланып, Җәбраил фәрештә белән Кәгъбәтулладан Кодыс шәһәрендәге Мәсҗиди Әксага күчә. Әкса мәчетендә икә рәкәгать намаз укый. Гадәти булмаган сәфәрнең шушы өлешенә “Исра” диелә.

Моннан соң Пәйгамбәребезнең мигъраҗы, ягъни күтәрелүе башлана. Ул Җәбраил фәрештә белән күкнең беренче катыннан җиденче катына кадәр менә. Аннан соң Сидрәтелмәнтәһа дигән урынга баралар. Бу урынга килгәч, Җәбраил фәрештә шулай ди: “Безнең һәрберебезнең билгеләнгән бер чиге бардыр. Минем чигем монда бетә. Мин моннан алга барсам, һәлак булырмын. Син Аллаһның чакырылучысы — Аллаһ сине чакырды. Син галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән бер пәйгамбәрсең. Син барырсың.” Шуннан соң Пәйгамбәребез мигъраҗ сәфәрен үзе генә дәвам итә. Аңа җәннәт белән җәһәннәм күрсәтелә. Ул Аллаһ белән сөйләшү бәхетенә ирешә.

Алар сөйләшкән сүзләрне хәзер барлык мөселманнар намазда — кәгъдәдә әттәхияткә утыргач әйтә.

Мигъраҗ кичәсендә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәдкә (с.г.в.) өч бүләк тапшыра:

1. Биш вакыт намаз фарыз кылына.
2. “Бәкара” сүрәсенең ахыргы икә аяте бирелә (285, 286 нчы аятьләр).
3. Мөхәммәд пәйгамбәргә Кыямәт көнендә үз өммәтен яклау хокукы, ягъни шәфәгать кылу мөмкинлеге бирелә.

Мигъраҗ — Аллаһка якын булуның иң өстен дәрәҗәседер, Мөхәммәд пәйгамбәребезнең иң зур могҗизаларыннан берседер.

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Хәерле холык – бәрәкәт нигезе

Адәм баласы дөнья-га яралтылганнан бирле аның янында менә дигән күркәм сыйфатлар белән бергә, яманнары да яшәп килә. Әлеге сыйфатлар хакында Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин белән сөйләшәбез.

- Әссәламугаләйкум! Әлфәс хәзрәт, сүзебезне замана авыруы — нәфес колы булу, шөкер итә белмәү кебек сыйфатларга бәя бирүдән башлыйк әле. Бүген өстәлләребез ризык муллыгыннан, киштәләребез кием-салымнан сыгылып тора, шулай да кешегә һаман нидер җитми, ул зарланудан бушамый...

- Әгуузу билләһи минәш-шәйтанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдү лилләһи Раббил гааләмиин, әссаләтү үәссәләәмү галәә расулиһи Мухәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсхәбиһи әҗмәгыйн.

Шөкер итә белү — мөселманның күркәм сыйфаты ул. Нәфесебез, сүз дә юк, күпне сорый, дөнья мәшәкатен кайгыртырга омтыла. Бу — хәзерге заман проблемасы гына түгел, һәрвакыт шулай булган. Тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән: кулыңа нинди генә мал керсә дә, аның Аллаһтан икәнен аңлап, шөкер итү сорала. Нинди дә булса авырлык килсә, анысы да Аллаһтан, аны да, сынау дип, сабырлык белән кабул итәргә кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) нәрсә ди: “Мөселманның тормышы гаҗәеп. Ул, бер яхшылык килсә, Аллаһка рәхмәт әйтә — саваплы була. Бер зарар килсә, сабыр итә — шулай ук саваплы була”.

Әби-бабайларыбыз бу ике сыйфатка да ия булган, тормышлары ничек кенә авыр чакларда да җидешәр-унышар бала тәрбияләп үстергәннәр, бер көнлек ризыклары булса — шуңа шөкер итә белгәннәр. Бүген, кызганыч, сез әйткәнчә, өстәлдә нинди ризык кирәк — барысы да бар, нәфес белән көрәшү юк. Кешенең күп кенә бәлаләре нәфескә “юк” дип әйтә белмәү, шөкер итмәү, канәгать булмау аркасында килеп чыга да инде.

- Нәфес янәшәсендә тагын бер ямьсез сыйфат — көнчеллек тә бер тотам калмый атлый бит әле...

- Көнчеллек — кешене эчтән ашый торган бер корт шикелле. Шөкер итә белмәгән кешегә башка берәүнеке һәрчак күп күренә, шуннан көнчеллек туа. Кешедә көнләшү бер генә нәрсәдә — гыйлем алуда гына булырга тиеш. Үзенең гыйлеме аз булуны танып, “бу кешенең гыйлеме күп, мин дә шундый гыйлем иясе булырга тиеш”, дисә — бу рөхсәт ителә, калган очракта — тыела. Чөнки көнләшү — ут шикелле, ул дуслык, туганлык, кардәшлек җепләрен яндыра, нәфрәт тудыра.

- Бездә, ямьсезрәк яңгыраса да, бер мәкаль яшәп килә: татар түрә булса, чабатасын түргә элә, диләр... Мин-минлек, тәкәбберлек кешенең үзе өчен ни дәрәҗәдә куркыныч сыйфатлар?

- Аллаһы Тәгалә әйтә: “Күңелендә орлык кадәр генә тәкәбберлек хисе булган кеше җәннәткә кермәс”, — ди. Күп кеше үзенең тәкәббергә әйләнгәнен абайламый да кала. Әйтик, аны гел мактап, күккә чөеп торсалар, тиле тиле дигән саен күккә сикерә дигәндәй, үзен әллә кем итеп тоя башлавы бик мөмкин. Шуңа күрә Пәйгамбәребез (с.г. в.) “Әгәр сезне мактый башласалар, аның күзенә тузан сибегез”, — дигән бит. Артык мактау мин-минлеккә китерә торган әйбер. Ә мин-минлек, тәкәбберлек нәкъ көнчеллек шикелле: намаз, ураза, хаҗ кебек хәерле гамәлләрне дә яндырырга мөмкин.

- Кызгану хисенә аерым тукталсак... Еш кына ата-ана сабый балаларын иртәнге намазга уятырга кызгана...

- Балага аз гына да авырлык килмәсен өчен ата-ана барысын да эшләргә риза. Аның бармак очы киселсә дә, утка-суга төшә. Тик баланы дөнья максатында гына түгел, ахирәт максатында да тәрбияләргә кирәк бит. Бала акны карадан аерырга өйрәнә башлагач, намазга бастыру, шуның өчен иртән дә уяту — аңа мәрхәмәт күрсәтү, аның киләчәген, мәңгелек ахирәтен кайгырту ул. Үзебез дә, дөньядан киткәч, балаларыбызның догаларына, дөньялыктагы гамәлләренә мохтаҗ булып калабыз. Аларны намазлы итеп тәрбияләү, Коръән укырга өйрәтү — ата-ананың бәхетле картлыгы, баланың бәхетле киләчәге.

- Ни зарлансак та, бүгенге көндә дә башкаларга ярдәм итүдән, эчкерсез булышудан тәм табучы шәфкатьле кешеләр очрап тора.

- Кемгә генә, нинди генә ярдәм күрсәтсәк тә, Аллаһ ризалыгы өчен дип эшләсәк, дәрәҗәләрәк, саваплырак була. Әйтик, берәү, мөмкинлеге булып, масаеп, “менә, мин бай” дип кемгәдер 100 мең сум акча бирергә мөмкин, икенче берәү, “аз гына булса да, Аллаһ ризалыгы өчен булсын, ярдәмемне кабул ит”, дип, мохтаҗ кешегә ун сум бирергә мөмкин. Матди яктан чагыштырсаң, әлбәттә, 100 мең күбрәк күренә, ә мәгънәви яктан уйласаң, ун сумның дәрәҗәсе, савабы, Аллаһ ризалыгы өчен бирелгәч, бик күпкә артык.

Һәр гамәлебез Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен булса, тормышка да бәрәкәт, иминлек киләчәк.

- Амин! Һәркемгә бары тик хәерле гамәлләр генә кылып яшәргә язсын!

Әңгәмәдәш — Айгөл Әхмәтгалиева.

ӘДӘБИ СҮЗ

Гөлүсә Батталова

Акыл керде безгә кичегеп

Кар өстенә ишеп яңгыр яуды,
Иртә килгән кышка үчегеп.
Юллар тайгак. Начар җайдак, ахры, –
Акыл керде безгә кичегеп.

Кар өстенә ишеп яңгыр яуды,
Эретмәкче булып дөньясын.
Өлгермәде. Бозга әйләнгәндә
Тамчылар да җуйды кыйбласын.

Болытларга карап мең рәнҗедек –
Юешләнде мамык бияләй.
Күкләр биек, уй җитмәслек биек,
Безгәме соң аны иярләү!

Мең мәшәкать төртеп тишеп чыккан
Мең ямаулы тормыш сүрүе –
Кар өстенә ишкән яңгыр төсле
Мең хыялның туңып сүнүе.

Кар өстенә ишеп яңгыр яуды,
Тарих белми, дидек, бу хәлне!
Сизми калдык, мәңгелекнең эзе
Боз астында калып күгәрде.

Сизми калдык, шушы тайгак көндә
Дөнья җыйган үзгә нәкышен.
Болытларга карап рәнҗегәндә
Күрдекме соң Күкләр рәнҗешен?!

***

Җаныбызда, рухыбызда
Исламның яктылыгы.
Җиребезне җәннәт итә
Күңелнең яхшылыгы.
Күкрәк сөте белән иңгән,
Калебне нурлый Иман.
Изгелекне, игелекне,
Кешене зурлый Ислам.
Иминлек сорап ил-көнгә
Аллаһка дога кылыйк.
Туган телле, туган җирле,
Намазлы милләт булыйк.

Гайбәтче кем ул?

Бер кеше Хәсән Басри хәзрәтләренең янына килеп:

– Фәлән синең турында начар сүзләр әйтте, - ди.

– Кайчан?

– Бүген.

– Кайда?

– Өендә.

– Аның өендә нишләдең?

– Кунакка бардым.

– Кунакта нәрсә ашадың?

Ул кеше сигез төрле ризык исемен саный.

Шунда Хәсән Басри:

– Ул адәмнең сигез төрле ризыгын эчеңә сыйдыргансың, ә бер сүз сыймадымы? Кит моннан, - ди һәм гайбәтчене куып чыгара.

Дога кабул булсын дисәң...

Кылган доганың кабул булуы өчен кешенең хәләл белән хәрәмне аера белүе шарт. Дога кылучы кеше һәр җәһәттән пакь булырга тиеш. Ягъни доганы кылган урын да, дога кылучының тәне һәм ашказаны да пакь булу кирәк. Аллаһ каршында доганың кабул булуы өчен бу ике шарт та үтәлергә тиеш.

Хәзрәте Гомәр бу турыда болай дигән:

- Тәнегездә һәм ашказаныгызда хәрәм булса, гыйбадәтегездән ләззәт ала алмассыз.

Сәхабәләрнең берсе Әнәс беркөнне Рәсүле Әкрам хәзрәтләреннән сораган:

- Догамның кабул булуын телим. Шуңа ирешүнең юлларын күрсәтмәссеңме?

- Йә Әнәс, хәләл акча эшлә, хәләл киен киен, хәләл ризык аша. Хәрәм киен кигән, ашказанында хәрәм ризык булган кешенең нафилә (өстәмә) гыйбадәте кырык көн кабул булмас. Догабыз кабул булсын дисәк, без дә хәрәмнән елан-чаяннан качкан кебек качарга, аннан читләшергә тиешбез!

Чит илләргә чыгып гыйбрәт ал

(Сәяхәтнамә)

Ислам кушканча, шәригать кануннарына муафыйк яшәү, тормыш итү рәвеше безгә әби-бабаларыбыздан гадәт ителгән. Коръән белән гамәл кыла башлагач, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в) сөннәте нигезендә яшәвебезне дәвам иткән хәлдә, гел бер уй күңелдән китми. Китаплардан гына укып аңлашылган мөселман мохите ничек була икән, ислам җәмгыятендә ничек яшиләр икән?!

Шул уйларым Аллаһның рәхмәте белән чынга да ашты. Кышкы салкын көннәрнең берсендә, самолет безне Гарәп Әмирлекләрендәге Дубай шәһәренә китереп төшерде. «Кунакка үз кадереңне белеп кил», ди халык. Гарәп мәдәниятен искә төшереп, телен, гадәтләрен хәтердә яңартып, самолеттан төштек. Ап-ак киемдәге, башларына кызыл шакмаклы яулык элгән гарәпләр бик матур каршы алды. Автобуска утырдык. Ком үләндә ямь-яшел, чәчәкләр дә үсә. Болытларга җиткән мәһабәт йортлар. Гаҗәпкә калып, күккә карыйм. Кыш ае булуга карамастан, кояш югары, кыздыра. Уйларым юлда очраган затлы машиналарга ияреп, гарәпчә язылган элмә такталарга төшә. Гарәпчә тәрҗемә итә алганыма куанып, укыйм: «Мактум» аэропорты, шәех Зәед урамы. Күңелне шатлык хисе биләп ала. Инде үзебез тукталачак кунакханәгә кергәч, елмаеп каршы алулары бу халыкның бик тә кунакчыл булуын күрсәтә.

Унҗиденче катның тәрәзәсеннән шәһәргә карыйм. Урам саен мәчет. Барлык биналар комсу алтын төстә.

Өйләгә азан яңгырый, бер мәчеттә әйтелгән азан икенче мәчеттәге азанга килеп кушыла: «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!». Йә Аллам, нинди бөексең!

Урамга чыгабыз. Ишек төбеннән такси сине теләгән җиреңә илтеп куярга әзер. Күңелнең көткәне — Абу-Даби шәһәрендәге Зәед шәех мәчете. Ап-ак мәрмәрдән төзелгән бу мәчет — чүл гарәпләренең күңел аклыгы, сафлыгы. Халык үзенең беренче җитәкчесенә хөрмәтен белдереп, кабере янына мәчет салдырган. Тәүлек

буена Коръән укыла. Кулларымны күтәрәм: «Йә Аллам! Нинди хөрмәт! Нинди мәрхәмәтлелек!». Башымны сәҗдәгә куям.

Берсеннән-берсе биек йортлар, заманча кунакханәләр, гөл бакчалары, ризык һәм кием кибетләре, ял парклары — санап бетергесез. Иң гаҗәбе — кызу, эссе чүлдә кар паркы. Бай гарәпләр кар күрергә шунда киләләр!?

Үзебезнең якка самолеттан килеп төшкәч тә, күзем ап-ак карга төшә. Елмаям һәм «әлхәмдүлилләһи Раббил галәмин, кар бит үзебезнеке!» дип кабатлыйм...

Гөлфия Насыйбуллина,
тел, әдәбият һәм сәнгать белгече.

Укы һәм уйлан!

Намаз — иң фазыйләтле гыйбадәтләрнең берсе, чөнки ул җәннәткә керүебезгә бер сәбәп булып тора. Кыямәт көнендә дә бездән иң беренчеләрдән булып намаз өчен хисап алыначак.

Намаз — нинди генә хәлдә һәм халәттә булсак та кылынырга тиешле гыйбадәт. Авырып китеп, басып укый алмасак, утырып укырга, утырып та укый алмасак, ятып укырга тиешбез. Намаз уку һичберкайчан өстебездән төшми.

Һәр бәлигъ яшькә җиткән, үз акылында булган мөселман кешесенә намаз уку фарыз. Укымаса, бу кеше гөнаһлы булачак. Раббыбыз әмер итеп әйтә: “Намазларны үтәгез, зәкәт сәдакасын бирегез һәм намаз укучылар белән бергә намаз укыгыз”.

(“Бәкара” сүрәсе, 43нче аять).

Дөньяда Аллаһы Тәгаләнең сүзеннән дә өстенрәк һәм Аның сүзеннән дә дөресрәк сүз юктыр. Аның сүзе иң дөрес һәм иң өстендер. Адәм баласына кайгы һәм хәсрәт үзенең кылган гөнаһлары сәбәбеннән килә. Моның турында безгә Аллаһы Тәгалә Коръәндә хәбәр бирде: “Әй мөәминнәр, сезгә ирешкән бәла-казалар һәм кайгы-хәсрәтләр үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпле”.

(Шура сүрәсе, 30 нчы аять).

БЕЛӘСЕЗМЕ?

Гыйбадәт өч төрле була:

1. Иман иясе үзе кыла торган гыйбадәт (тән белән кылынган гыйбадәт). Мәсәлән, намаз кылу яки ураза тоту кебек. Һәрбер мөселман бу гыйбадәтләрне үзе кылырга тиеш, аларны бүтән кешегә тапшырып булмый. Башка берәү өчен ураза тотарга яки намаз укырга ярамый.

2. Мал-мөлкәткә бәйле гыйбадәт. Моңа зәкәт түләү һәм корбан чалу керә. Мал-мөлкәткә бәйле гыйбадәтне башка берәүгә тапшырырга рөхсәт ителә.

3. Иман иясе үзе кыла торган һәм мал-мөлкәткә бәйле гыйбадәт (тән һәм мал белән кылган гыйбадәт). Моңысы – Мәккәгә барып хаҗ кылу. Өлкән яшьтәге, авыру яки гарип кешеләр, акчасы була торып та, хаҗ кылырлык хәлдә булмаса, үзләре урынына хаҗ кылуны бүтән бер мөселманга тапшыра ала.

Балалар өчен

Алинә Фәсхиева

“Дөнья мәчетләре буйлап” циклыннан

Сөләймания мәчете

(Истанбул шәһәре, Төркия)

Архитектор Синан эше –
Мәчет манаралары.
Искә төшерә османнарның
Чәчәк аткан чорларын.
Данлы солтанның исемен
Биш гасыр буе йөртә.
Бүген дә дәшә намазга,
Чакырып торган элек тә.
(Ф.Мөслимова тәрҗемәсе)

ТӨСЛЕ КАЛӘМ БЕЛӘН БУЯГЫЗ

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР

Баш мөхәррир
Айгөл Абдуллина

Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы 1280.

Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, таныш-ларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:

423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
27 март 16 сәг.
фактта 27 март 16 сәг.

Бәясе ирекле